ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» май 2018ел. № _237_

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълумат чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү кагыйдәләрен раслау турындагы Карарга (12. 08. 2013. 284) үзгәрешләр кертү турында

“Реклама турында“ Федераль законга (13. 03. 2006 38-ФЗ) нигезләнеп һәм реклама конструкцияләрен, тышкы реклама һәм мәгълумат чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүне тәртипкә салу максатында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълумат чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүне тәртипкә салу турындагы Карарга (12.08. 2013 284) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру схемасына, элек кертелмәгән мәгълумат өстәп, үзгәрешләр кертергә.
2. Россия Федерациясе субъекты милкендә яки муниципаль милектә булган Әгерҗе муниципаль районындагы җир участокларында, биналарда һәм күчемсез милектәге реклама конструкцияләрен үзгәрешләр белән урнаштыру схемасын расларга.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълуматлаштыру чаралары Җыентыгын расларга.
4. Карарны сайтында һәм ТР хокукый мәгълумат порталына урнаштырырга.
5. Карарны тормышка ашыруга контрольне үземнең өстә калдырам.

Җитәкче А. С. Авдеев.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты Карары (31.05 2018. 237) белән расланган

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру
СХЕМАСЫ

1. Схеманы куллану сферасы

“Реклама турындагы“ Федераль Законның 19 маддәсе положениеләре нигезендә әлеге схема Әгерҗе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру урыннарын билгели.

Схема щитлар, стендлар, электрон таблолар һәм тышкы рекламаныц башка техник чараларын кулланып реклама таратканда кулланыла.

Схема корылмалардан читтәге территориядә торучы реклама конструкцияләренә кулланыла. Схеманы кулланганда реклама конструкциясенең тышкы күренеше һәм урыны урнаштыру предметы булып санала.

Схема:

Реклама конструкцияләренең торен билгеләүче аңлатма запискадан һәм схемага үзгәрешләр кертүне таләп итүче очраклар исемлегеннән ;

Карталар һәм башка график материаллардан;

Реклама конструкцияләре исемлегеннән;

Чаралар җыентыгыннан тора.

Схемада гамәлдә булган реклама конструкцияләре һәм аларны урнаштыру мөмкин булган урыннар яктыртылган.

2. Терминология

Тышкы реклама (реклама конструкцияләре) – биналар, төзелешләр һәм корылмаларның тышкы стеналарына, түбәләренә һәм башка конструктив элементларына урнаштырылган мәгълумат бирүче элементлары булган щит конструкцияләре, стендлар, тумблар, панель-кронштейннар, стена паннолары, баннерлар, электрон таблолар, проект конструкцияләре. Аларда хәрәкәт маршруты һәм анда урнашкан объектлар күрсәтелә.

Реклама кыры – реклама таратуяки мәгълумат урнаштыру өчен билгеләнгән реклама конструкциясе өслеге.

Реклама конструкциясе төрләре – мәгълуматны урнаштыру ысулы, реклама кыры мәйданына бәйле реклама конструкцияләре классификациясе.

Үзенә тарту объекты – предприятие, халыкка хезмәт күрсәтү объектлары, социаль мөһим объект, җәмәгать транспорты тукталышы, массакүләм чаралар үткәрү урыннары, мәдәни мирас объектлары.

3. Реклама конструкцияләре төрләре.

Әлеге Схеманы куллану максаты өчен реклама конструкцияләренең түбәндәге төрләре билгеләнелә:

1) Аерым торучы эре габаритлы – реклама кырының иң озын ягыннан 6 м һәм артыграк яки мәйданы 18 кв.м һәм күбрәк булган стелла, щит, электрон таблолар. Реклама конструкцияләренең бу төренә реклама тармагында кабул ителгән щитларның стандарт конструкцияләре исемнәре дә керә – суперборд, суперсайт, еврощит, аркалар. Юлның бер ягына аерым урнаштырылган тышкы реклама чаралары арасы кимендә 150 метр булырга тиеш.

2) Аерым торучы урта габаритлы – реклама кырының иң озын ягыннан кимендә 6 м , 3-18 кв.м мәйданлы стела, щит, электрон таблолар. Реклама конструкцияләренең бу төренә реклама тармагында кабул ителгән щитларның стандарт конструкцияләре исемнәре дә керә. Юлның бер ягына аерым урнаштырылган тышкы реклама чаралары арасы кимендә100 м булырга тиеш.
3) Аерым торучы кече габаритлы – 3 кв.м мәйданлы стела, щитлар, үзенә тартып торучы объектлар турында мәгълумат билгеләре, тумб, стенд, реклама модуле булган күрсәткечләр. Реклама конструкцияләренең бу торенә реклама тармагында кабул ителгән стандарт конструкция исемнәре – пилларс, пилон керә. Юлныц бер ягына аерым урнаштырылган тышкы реклама чаралары арасы кимендә 30 м булырга тиеш.

4. Реклама конструкцияләрен урнаштыруга таләпләр.

Реклама конструкцияләрен урнаштыру түбәндәге норматив документларга нигезләнеп башкарыла:

1) “Реклама турында“ Федераль закон (13.03.2006. 38-ФЗ);
2) ГОСТ Р 52044-2003. “Автомобиль юлларында, шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрендә тышкы реклама. Тышкы реклама чараларына гомуми техник таләпләр. Урнаштыру кагыйдәләре.“
3) ГОСТ Р 52044-2003 һәм норматив документлар нигезендә саклана торган электр челтәре, элемтә линияләре, газ бүлү челтәрләре зоналарында реклама чараларын урнаштыру тыела:

1) “Электр челтәре хуҗалыгы объектларының саклана торган зоналарын билгеләү һәм әлеге зона чикләрендәге җир участокларын куллануның аерым шартларын билгеләү тәртибе турында“ РФ Хөкүмәте Карары (24 февраль 2009ел 160);
2) “ Россия Федерациясе элемтә линияләре һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында“ Карар (9 июнь 1995 ел, 578 пункт);
3) “Газ бүлү челтәрләрен саклау Кагыйдәләрен раслау турында“ РФ Хокүмәте Карары (20 ноябрь 2000 ел. 878) .

Электр челтәрләре, элемтә линияләре, газ бүлү челтәрләренең саклана торган зоналарында төзелеш һәм теләсә нинди объект, шул исәптән реклама конструкцияләре урнаштыру да тыела.

Схемада реклама конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителә торган урыннар шартлы билге белән күрсәтелгән. Реклама конструкцияләрен урнаштыруның төгәл урыны җир асты һәм җир өсте челтәрләрен, юл полотносына һәм капиталь төзелеш объектларына карата интервалларны исәпкә алып билгеләнелә.

Автомобиль юлларының юл полосасында реклама конструкцияләре урнаштырганда хезмәт күрсәтүче оешмадан килешү алырга кирәк.

5. Схемага үзгәрешләр кертү.

Реклама конструкцияләрен урнаштыруны билгеләүче карта, график материаллар эчтәлегенә үзгәрешләр кертү “Реклама турында“гы Федераль закон нигезендә билгеләнелә.

Шулай ук түбәндәге очракларда Схемага үзгәрешләр кертү таләп ителә:

рөхсәт ителгән урыннарда яца реклама конструкцияләре урнаштыру – реклама конструкцияләреләре исемлегенә үзгәрешләр кертү;

Әгерҗе муниципаль районы территориясе өлешендә Схеманы карталар белән тулыландыру – 6 бүлеккә үзгәрешләр кертү;

реклама урнаштыру мөмкинлеге бирә торган төзелешләр башлану, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру – график материалларга үзгәрешләр кертү (реклама конструкциясе нең шартлы билгесен үзгәртү яки аны алып кую);
реклама конструкцияләренең санына корректировка кертү мөхимлеге – 3нче бүлеккә һәм график материалларга үзгәрешләр кертү (шартлы билгегә үзгәрешләр кертү яки аны алып кую).
6. Схема карталарының составы
1 бит. Әгерҗе шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру Схемасы.
2 бит. Әгерҗе муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру Схемасы.

## РЕКЛАМА КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕ ИСЕМЛЕГЕ

ПИЛОН – эчке яктан ут белән яктыртылган, фундаментта, аерым торучы кече форматтагы, 1,0x1,5 м үлчәмдәге типовой реклама конструкциясе.
Пилонның яклары икедән артык булырга тиеш түгел.
Пилонның фундаменты җирдән югары булмаска тиеш.

ЕВРОЩИТ – тышкы һәм эчке яктан яктыртылган, фундаменты, каркасы, мәгълумат кыры 3,0x6,0м үлчәмендә булган, зур форматтагы аерым торучы реклама конструкциясе.
Еврощитның яклар саны икедән артмаска тиеш.
Еврощит каркасының астагы кыры җир өстеннән кимендә 4,5м биеклектә урнашырга тиеш.

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитеты Карары (31.05.2018. 237) белән расланган

ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ УРНАШТЫРЫЛА ТОРГАН ТЫШКЫ РЕКЛАМА ҺӘМ МӘГЪЛУМАТ ЧАРАЛАРЫ ҖЫЕНТЫГЫ

ЕВРОЩИТ – фундаменттан, каркастан һәм мәгълумат кыры үлчәме 3х6 м булган аерым торучы тышкы реклама һәм мәгълумат чарасы.

Реклама конструкциясенең төп характеристикасы.
Үлчәме:
- мәгълумат кыры үлчәме – 3х6м;
- мәгълумат кыры каркасы үлчәме – 3,4х6,4 метрдан артык түгел.

Призматрон нигезендә өске өлеше өчен:
- мәгълумат кыры – 3,2х6 м;
- мәгълумат кыры каркасы үлчәме – 3,6х6,4 метрдан артык түгел.

Төп элемент – терәк стойкасы:
- 180-300 мм лы туры почмаклы торбадан яки 219-325 мм лы түгәрәк профиль торбадан ясалган;
- биеклеге – 4,5-6,0 м;
- төсе – соры;
- мәгһлумат кыры каркасының түбәнге кромкасына туры почмак белән урнаштырыла.

Реклама конструкциясен ут белән яктырту.
Реклама конструкциясе тышкы яки эчке яктан ут белән яктыртылырга тиеш. Тышкы яктан яктырту ике яки дүрт яктырткыч белән башкарыла. Соры төстәге яктырткычлар кулланырга тәкъдим ителә.

ПИЛОН – фундаменты, каркасы, 1,0х1,5м үлчәмендә мәгълумат кыры булган аерым торучы тышкы реклама чарасы.

Реклама конструкциясенең төп билгеләмәсе.
Үлчәмнәре:
- мәгълумат кыры үлчәме – 1,0х1,5 м
- мәгълумат кыры каркасы үлчәме – 1,25х1,75 метрдан артмаска тиеш.

Төп элемент – терәү стойкасы:
- стойка биеклеге – 600-1200мм;
- конструкция төрле куркынычсыз булган материаллар белән (металл, пластик һ.б.лар) тышлана;
- тышлау һәм терәү стойкасы төсе – караңгы соры металлик яки бронза төсендәге металлик.

Дизайн вариантлары:

- конструкция дизайны, мәгълумат кыры үлчәмнәрен үтәп, шәхси проект буенча эшләнергә мөмкин;
- дизайнны ӘМР Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге белән раслау мәҗбүри.

Реклама конструкциясенең яктыртылуы:

- реклама конструкциясе эчке яктан  ут белән яктыртылырга тиеш;
- электр кабеле җир астыннан узарга тиеш.